ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ
НОВОИГЛАЙКИНСКОГО
СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ
НУРЛАТСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
НУРЛАТ МУНИЦИПАЛЬ
РАЙОНЫ
ЯНА ИГЛАЙ АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ
БАШКАРМА КОМИТЕТЫ

---

ПОСТАНОВЛЕНИЕ

Яңа
Иглай авылы

БОЕРЫК

03.02.2020

№ 3

Татарстан Республикасы Нурлат муниципаль районы Яңа Иглай авыл җирлегендә җирләү буенча хезмәтләрнең гарантияле исемлеге нигезендә күрсәтелә торган хезмәтләр кыйммәтен раслау турында

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль закон, «Җирләү һәм җирләү эше турында» 1996 елның 12 гыйнварындагы 8-ФЗ номерлы федераль закон, «Татарстан Республикасында күмү һәм җирләү эше турында «Федераль законны гамәлгә ашыру чаралары хакында» 2007 елның 18 маендагы 196 номерлы Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты карары, Россия Федерациясе Хөкүмәтенең «2020 елда түләүләрне, пособиеләрне һәм компенсацияләрне индексацияләү коэффициентын раслау турында» 2020 ел, 29 гыйнвар, 61 номерлы карары нигезендә

КАРАР БИРӘМ:

1. Нурлат муниципаль районының Яңа Иглай авыл җирлегендә 2020 елның 1 февраленнән җирләү буенча хезмәтләрнең гарантияле исемлеге буенча күрсәтелә торган хезмәтләрнең бәясен 1нче һәм 2 нче кушымта нигезендә 6124,86 сум күләмендә билгеләргә һәм гамәлгә кертергә.

2. Татарстан Республикасы Нурлат муниципаль районы Яңа Иглай авыл җирлеге Башкарма комитетының «Татарстан Республикасы Нурлат муниципаль районы Яңа Иглай авыл җирлегендә җирләү буенча хезмәтләрнең гарантияле исемлеге нигезендә күрсәтелә торган хезмәтләрнең хакын раслау турында» 2019 елның 23 апрелендәге 14нче карары 2020 елның 1 февраленнән үз көчен югалкан дип санарга.

3. Әлеге карарны Нурлат муниципаль районының Яңа Иглай авыл җирлеге территориясендә мәгълүмат стендларында игълан итәргә һәм Татарстан Республикасы Нурлат муниципаль районының рәсми сайтында урнаштырырга.

4. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үз җаваплылыгымда калдырам.

Татарстан Республикасы
Нурлат муниципаль районы
Яңа Иглай авыл җирлеге
Башкарма комитеты җитәкчесе Ф.С. Гайнуллин

Нурлат муниципаль районы Яңа Иглай авыл җирлеге Башкарма комитетының 2020 елның 3 февралендәге 3 номерлы карарына 1 нче кушымта

2020 елның 1 февраленнән Татарстан Республикасы Нурлат муниципаль районы Яңа Иглай авыл җирлегендә җирләү буенча хезмәтләрнең гарантияле исемлеге
*(православие йоласы буенча)*

| Хезмәт күрсәтү исеме | Хезмәт күрсәтү бәясе |
|---|---|
| 1. Җирләү өчен кирәкле документларны рәсмиләштерү | 0,0 |
| 2. Табутны һәм җирләү өчен кирәкле башка предметларны китереп бирү | 2340,33 |
| 3. Мәетне (җәсәдне) зиратка илтү | 944,51 |
| 4. Җирләү  хезмәте (кабер казу һәм  җирләү ) | 2840,02 |
| Барлыгы | 6124,86 |

Нурлат муниципаль районы Яңа Иглай авыл җирлеге Башкарма комитетының 2020 елның 3 февралендәге 3 номерлы карарына 2 нче кушымта

2020 елның 1 февраленнән Татарстан Республикасы Нурлат муниципаль районы Яңа Иглай авыл җирлегендә җирләү буенча хезмәтләрнең гарантияле исемлеге
*(мөселман йоласы буенча)*

| Хезмәт күрсәтү исеме | Хезмәт күрсәтү бәясе |
|---|---|
| 1. Җирләү өчен кирәкле документларны рәсмиләштерү | 0,0 |
| 2. Мәетне кәфенләү (төрү) | 1112,58 |
| 3. Җирләү өчен кирәкле әйберләрне бирү һәм китерү | 1227,75 |
| 4. Мәетне (җәсәдне) зиратка илтү | 944,51 |
| 5. Җирләү хезмәте (кабер казу һәм җирләү ) | 2840,02 |
| Барлыгы | 6124,86 |